Мордовиядә матур татар гаиләләре байтак. Менә тагы берләре турында – Кадошкино районы Большие Поляны авылынын гади һәм тыйнак гаиләләренен берсе булган Румия белән Тахир Альмяшевлар. Кулга-кул тотынышып гомер козләренә парлы сукмактан атлаучы гаиләләр соклану уята. Илле беренче ел бергә, бердәм булып яшәv очен сабырлык та, vзара ихтирам да кирәк.
Ирле-хатынлы хезмәт ветераннары Таһир Хосәен улы белән Равилә Фәрит кызы Альмяшевлар ярты гасырдан артык бергә яшиләр. Парлы гомер – бәхет ул. Алар гомер буе vзләренен кече ватанында яшиләр, анда тырышып хезмәт иткәннәр. Авылларынын чын патриотлары. Тахир Хосәен улы хезмәт соючән кvп балалы гаиләдә туып vскәнгә, кечкенәдән әти-әнисенә ярдәм итәргә тырышып торле йорт-бакча хезмәтен vтәп килгәнгә эштә чыныккан. Хезмәт биографиясен Нариманов исемендәге колхозда башлаган булса, «Победа» колхозында дәвам итә ул. Эштән курыкмаган, торлесен башкарган. Авыллары колхозы бензовозында техника очен бензин ташыган. Аннары берничә дистә ел колхоздагы торле эшләрне дә башкарырга туры килә ана: фермада терлек азыгы оләшv буенча оператор булган, сонрак колхоз котvен саклаган. Шушы чорда колхозларда терлекләр кvп иттереп асраганнар – сарыклар, савым сыерлары, бозаулар... Хайваннарнын саны, котvләрнен зурлыгы буенча Кадошкино районында беренчелекне “Победа” колхозы токкан, шуна Тахир Хосәен улына эш житәрлек булган. Нинди генә һава торышы булмасын: янгыр, эссе коннәрдә я атка атланып, я жәяv генә һәр конне иртә таннан кояш батканчыга кадәр, я жәйге то